Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 3**

Балыклы-Чүкәй авылы 7 декабрь, 2021 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Советының 2014 елның 16 октябрендәге “Җир салымы турында”гы 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, 2021 елның 7 июлендәге “Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 305-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Советының 2014 елның 16 октябрендәге “Җир салымы турында”гы 8 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның 2 абзацында “, шулай ук күрсәтелгән объектларны урнаштыру өчен аталган җир кишәрлекләре” сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карар рәсми игълан ителгән (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның салым чорындагы җир салымын исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлегенең Балыклы-Чүкәй авылы, Үзәк урам, 8 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Башлыгы И.С.Мазитов